Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 12**

Шумково_авылы                07 август 2024

Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Шумково___авыл җирлеге Советының 2017 елның 04 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы ____авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен әүзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм кулану калдыклары турында»1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законнар ,Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар беләнэ шитү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 25 августындагы 641 номерлы карарына үзгәреш кертү турында» 2016 елның 12 ноябрендәге 1156 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Шумково_авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Шумково авылҗирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Шумково авылҗирлеге Советының 2017 елның 04 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы Шумково_авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (15.11.2018 ел № 12; 13.08.2018 ел № 11; 02.11.2020 ел № 23 карарлар ред.) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) түбәндәгеэчтәлектәге 4.6.1.9 - 4.6.1.12 пункт чаларны өстәргә:

«4.6.1.9. Контейнер капкачы ябылганчы булган күләменә кадәргенә тутырылырга тиеш (контейнерның өске кырыеннан югары түгел). Контейнердагы калдыкларны мусоровозга бушатканда, аларны коеп, төшереп булмаслык итеп,тутыру барышында пресслау яки тыгызлап төю һәм куелган күләмнән артык контейнерны тутыру тыела.

4.6.1.10. Каты коммуналь калдыклар өчен контейнерларга эре габаритлы калдыклар, автомобиль шиннары һәм покрышкалар, сыек матдәләр, авыл хуҗалыгы калдыклары, биологик калдыклар, биологик һәм химик актив калдыклар,терекөмеше булган яктырту приборлары һәм электр лампалары, ток (батарея һәм аккумуляторлар) химик чыганаклары, медицина калдыклары, үсемлек калдыклары, җир кишәрлекләрендә эшләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән калдыклар, төзелеш калдыклары урнаштыру тыела.

4.6.1.11. Каты коммуналь калдыкларны һәм эре габаритлы калдыкларны, шулай ук 4.6.1.10 пунктында күрсәтелгән калдыкларны контейнерлардан һәм бункерлардан тыш урнаштыру (ташлау, ыргыту) тыела.

4.6.1.12. Төзелеш чүп-чарларын һәм контейнерларга яки бункерларга урнаштыру тыелган башка төр чүп-чарны чыгару калдыкларның хуҗалары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә яисә коммуналь хезмәтләргә үз хисабыннан полигоннарга заявка бирү юлы белән башкарыла(калдыкларны урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар).»;

1.2) 4.6.1.9-4.6.1.14 пунктчаларын тиңдәшле рәвештә 4.6.1.13-4.6.1.18 пунктчалары дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Шумково авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Шумково авылы, Үзәк урам, 4 йорт; Олы Укмас авылы, Үзәк урам, 42 йорт; Хутор авылы, Яшьләр урамы, 5 йорт; Әшнәк-Качкалак авылы, Югарыгы урам, 5 йорт йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Шумково авыл җирлеге башлыгы урынбасары ___________ Моталлапов Н.Н.